**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О регулировании отдельных вопросов в области ведения гражданами садоводства и огородничества для собственных нужд в Республике Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
15 июня 2022 года

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон регулирует отдельные вопросы в области ведения гражданами садоводства и огородничества для собственных нужд в Республике Татарстан (далее – садоводство и огородничество).

Статья 2. **Правовое регулирование отношений в области ведения гражданами садоводства и огородничества**

Правовое регулирование отношений в области ведения гражданами садоводства и огородничества осуществляется Федеральным законом от 29 июля 2017 года № 217-ФЗ «О ведении гражданами садоводства и огородничества для собственных нужд и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации», другими федеральными законами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, настоящим Законом и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также нормативными правовыми актами органов местного самоуправления.

Статья 3. **Полномочия Государственного Совета Республики Татарстан в области ведения гражданами садоводства и огородничества**

К полномочиям Государственного Совета Республики Татарстан в области ведения гражданами садоводства и огородничества относятся:

1) законодательное регулирование отношений в области ведения гражданами садоводства и огородничества;

2) осуществление контроля за соблюдением и исполнением законов Республики Татарстан, регулирующих отношения в области ведения гражданами садоводства и огородничества;

3) осуществление иных полномочий, предусмотренных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 4. **Полномочия Кабинета Министров Республики Татарстан в области ведения гражданами садоводства и огородничества**

К полномочиям Кабинета Министров Республики Татарстан в области ведения гражданами садоводства и огородничества относятся:

1) утверждение государственных программ Республики Татарстан, предусматривающих мероприятия, направленные на поддержку ведения гражданами садоводства и огородничества;

2) определение органа исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченного в области ведения гражданами садоводства и огородничества (далее – уполномоченный орган);

3) утверждение порядка безвозмездного приобретения имущества общего пользования, расположенного в границах территории ведения гражданами садоводства или огородничества для собственных нужд (далее – территория садоводства или огородничества), в государственную собственность Республики Татарстан или муниципальную собственность;

4) определение средств массовой информации, в которых может быть размещено сообщение о проведении общего собрания членов садоводческого или огороднического некоммерческого товарищества (далее – товарищество);

5) осуществление иных полномочий, предусмотренных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 5. **Полномочия уполномоченного органа в области ведения гражданами садоводства и огородничества**

К полномочиям уполномоченного органа в области ведения гражданами садоводства и огородничества относятся:

1) разработка государственных программ Республики Татарстан, предусматривающих мероприятия, направленные на поддержку ведения гражданами садоводства и огородничества;

2) реализация на территории Республики Татарстан государственной поддержки ведения гражданами садоводства и огородничества;

3) взаимодействие с федеральными органами государственной власти, органами государственной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления в Республике Татарстан по вопросам ведения гражданами садоводства и огородничества;

4) обращение в суд с иском о ликвидации товарищества в случае несоблюдения требования к количеству членов товарищества, установленного частью 2 статьи 16 Федерального закона от 29 июля 2017 года № 217-ФЗ «О ведении гражданами садоводства и огородничества для собственных нужд и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации»;

5) осуществление иных полномочий, предусмотренных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 6. **Государственная поддержка ведения гражданами садоводства и огородничества**

1. В целях оказания государственной поддержки ведения гражданами садоводства и огородничества органы государственной власти Республики Татарстан вправе:

1) создавать в своей структуре подразделения, обеспечивающие реализацию республиканской политики по поддержке ведения гражданами садоводства и огородничества;

2) принимать государственные программы Республики Татарстан, предусматривающие мероприятия, направленные на поддержку ведения гражданами садоводства и огородничества, в том числе инвестиционные программы;

3) вести просветительскую работу в целях популяризации ведения гражданами садоводства и огородничества;

4) организовывать в границах территории садоводства или огородничества снабжение тепловой и электрической энергией, водой, газом, водоотведение, снабжение топливом в пределах полномочий, установленных законодательством Российской Федерации;

5) осуществлять финансирование выполнения комплексных кадастровых работ применительно к кадастровым кварталам, в границах которых расположены территории садоводства или огородничества;

6) по заявлению товарищества или участников общей долевой собственности на имущество общего пользования, расположенное в границах территории садоводства или огородничества, безвозмездно приобретать в государственную собственность Республики Татарстан такое имущество общего пользования (автомобильные дороги, объекты электросетевого хозяйства, водоснабжения, связи и другие объекты) в случае, если такое имущество в соответствии с законодательством Российской Федерации может находиться в государственной собственности;

7) осуществлять поддержку ведения гражданами садоводства и огородничества в иных формах, установленных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

2. Государственная поддержка ведения гражданами садоводства и огородничества предоставляется за счет средств бюджета Республики Татарстан, предусмотренных законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на соответствующий финансовый год и на плановый период.

3. Порядок осуществления мер государственной поддержки ведения гражданами садоводства и огородничества, предусмотренных частью 1 настоящей статьи, устанавливается Кабинетом Министров Республики Татарстан.

4. Меры государственной поддержки в отношении территорий садоводства и огородничества, в границах которых садовые земельные участки и огородные земельные участки принадлежат исключительно гражданам, имеющим право на их

внеочередное, первоочередное или иное льготное приобретение, оказываются в приоритетном порядке.

Статья 7. **Принципы государственной поддержки ведения гражданами садоводства и огородничества**

Основными принципами государственной поддержки ведения гражданами садоводства и огородничества являются:

1) адресность и целевой характер государственной поддержки;
2) равный доступ к государственной поддержке;
3) открытость процедур оказания государственной поддержки;
4) сочетание финансовых и иных мер государственной поддержки;
5) оказание государственной поддержки с соблюдением требований, установленных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 8. **Муниципальная поддержка ведения гражданами садоводства и огородничества**

1. Органы местного самоуправления вправе осуществлять муниципальную поддержку ведения гражданами садоводства и огородничества в формах, предусмотренных законодательством Российской Федерации.
2. Муниципальная поддержка ведения гражданами садоводства и огородничества предоставляется за счет средств местных бюджетов.
3. Порядок осуществления мер муниципальной поддержки ведения гражданами садоводства и огородничества устанавливается органами местного самоуправления.

Статья 9. **Признание утратившей силу статьи 6 Закона Республики Татарстан «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан в связи с принятием Федерального закона «О ведении гражданами садоводства и огородничества для собственных нужд и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации»**

Признать утратившей силу статью 6 Закона Республики Татарстан от 22 декабря 2018 года № 114-ЗРТ «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан в связи с принятием Федерального закона «О ведении гражданами садоводства и огородничества для собственных нужд и о внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации» (Собрание законодательства Республики Татарстан, 2019, № 2 (часть I).

Статья 10. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
21 июня 2022 года
№ 35-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 июнендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасында гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек (алга таба – бакчачылык һәм яшелчәчелек) белән шөгыльләнүе өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, шулай ук җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе

өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм башкаруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4 статья. **Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар каралган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендәге вәкаләтле органын (алга таба – вәкаләтле орган) билгеләү;

3) гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе (алга таба – бакчачылык яисә яшелчәчелек территориясе) чикләрендә урнашкан гомуми файдаланудагы мөлкәтне Татарстан Республикасы дәүләт милкенә яисә муниципаль милеккә түләүсез алу тәртибен раслау;

4) коммерциягә карамаган бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәте (алга таба – ширкәт) әгъзаларының гомуми җыелышын үткәрү турында хәбәр урнаштырылырга мөмкин булган массакүләм мәгълүмат чараларын билгеләү;

5) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

5 статья. **Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә вәкаләтле орган вәкаләтләре**

Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендәге вәкаләтле орган вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар каралган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү;

2) Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыру;

3) гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнү мәсьәләләре буенча федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итү;

4) «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль

законның 16 статьясындагы 2 өлешендә ширкәт әгъзалары санына карата билгеләнгән таләп үтәлмәгән очракта, ширкәтне бетерү турындагы дәгъва белән судка мөрәҗәгать итү;

5) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

6 статья. **Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә дәүләт ярдәме**

1. Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) үз структурасында гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә ярдәм итү буенча республика сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итүче бүлекчәләр төзергә;

2) гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар каралган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын, шул исәптән инвестиция программаларын, кабул итәргә;

3) гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүен популярлаштыру максатларында агарту эше алып барырга;

4) бакчачылык яисә яшелчәчелек территориясе чикләрендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җылылык һәм электр энергиясе, су, газ белән тәэмин итүне, су җибәрүне, ягулык белән тәэмин итүне оештырырга;

5) чикләрендә бакчачылык яисә яшелчәчелек территорияләре урнашкан кадастр кварталларына карата комплекслы кадастр эшләрен үтәүне финанслауны башкарырга;

6) бакчачылык яисә яшелчәчелек территориясе чикләрендә урнашкан гомуми файдаланудагы мөлкәт Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт милкендә булырга мөмкин булган очракта, ширкәтнең яисә мондый гомуми файдаланудагы мөлкәткә гомуми өлеш милкендә катнашучыларның гаризасы буенча мондый гомуми файдаланудагы мөлкәтне (автомобиль юллары, электр челтәре хуҗалыгы объектлары, су белән тәэмин итү объектлары, элемтә объектлары һәм башка объектлар) Татарстан Республикасы дәүләт милкенә түләүсез алырга;

7) гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә ярдәм итүне Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка рәвешләрдә башкарырга.

2. Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә дәүләт ярдәме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән күрсәтелә.

3. Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә әлеге статьяның 1 өлешендә каралган дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

4. Чикләрендә бакча җир кишәрлекләрен һәм яшелчә җир кишәрлекләрен бары тик чираттан тыш, беренче чиратта яисә башка ташламалы сатып алу хокукы булган гражданнар гына ия булган мондый җир кишәрлекләре урнашкан бакчачылык һәм яшелчәчелек территорияләренә карата дәүләт ярдәме чаралары өстенлекле тәртиптә күрсәтелә.

**7 статья. Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә дәүләт ярдәме принциплары**

Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә дәүләт ярдәме төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) дәүләт ярдәменең адреслылыгы һәм максатчан характерга ия булуы;

2) дәүләт ярдәменнән бертигез дәрәҗәдә файдалана алу;

3) дәүләт ярдәме күрсәтү процедураларының ачыклыгы;

4) дәүләт ярдәменең финанс чараларын һәм башка чараларын бергә алып бару;

5) дәүләт ярдәмен, Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләрне үтәп, күрсәтү.

**8 статья. Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә муниципаль ярдәм**

1. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе законнарында каралган рәвешләрдә гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә муниципаль ярдәм күрсәтергә хокуклы.

2. Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә муниципаль ярдәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән күрсәтелә.

3. Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүенә муниципаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру тәртибе җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

**9 статья. «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясының үз көчен югалтуын тану**

«Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 22 декабрендәге 114-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының

6 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2, (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

10 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 21 июнь
№ 35-ТРЗ